ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2025 г.Казань № 6-1/т-2025

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 19.03.2025 ел, №3-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 07.10.2020 №106-3/т-2020, 03.02.2021 №1-1/т-2021, 09.12.2021 №478-17/т-2021, 25.05.2022 №69-8/т-2022, 24.08.2022 №143-21/т-2022, 01.09.2023 №126-5/т-2023 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә кертелә торган, кушымтадагы үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
19.03.2025 № 6-1/т-2025
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2019 елның 7 июнендәге 7-1/т номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими маршрутлар буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруга җайга салынулы тарифлар билгеләү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

13 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Заказчы ел саен җайга салуның чираттагы чорына кадәрге елның 1 сентябренә кадәр Дәүләт комитетына тарифлар билгеләү турында тәкъдим кертә.»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Тарифлар билгеләү һәм тапшырылган документларны һәм материалларны кире кайтару турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту турында Карар кабул итү өчен нигез булып заказчының тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимне тапшыруның әлеге Тәртиптә билгеләнгән срокларын үтәмәве, Дәүләт комитетына әлеге Тәртипнең 21 һәм 27 пунктларында каралган документларның һәм материалларның тулы булмаган күләмен тапшыру, пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлегенә чыгымнарның, пассажирлар йөртүчеләрнең башка эшчәнлек төрләренә чыгымнарының аерым исәпкә алынмавы тора.

19 пунктта:

бишенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Заказчы үз инициативасы белән Дәүләт комитетына агымдагы елның 15 октябренә кадәр, әмма Дәүләт комитеты идарәсе утырышын уздыру көненә кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, тарифлар билгеләү турындагы тәкъдимгә өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

Тиешле өстәмә материаллар һәм белешмәләр тарифлар билгеләү турындагы эшкә теркәп куела.»;

20 пунктның беренче-икенче абзацларында «30 календарь көн» сүзләрен «30 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктта «21 пунктында» сүзләрен «21 һәм 27 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктның икенче абзацын түбәндәгечә бәян итәргә:

«Карар проекты буенча фикер каршылыклары булганда заказчы, мәнфәгатьле республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары Дәүләт комитетына аның «Бәяләрне (тарифларны) билгеләү турында карарлар кабул итү регламентын һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының башка карарларын раслау турында» 22.07.2021 №450/2021 боерыгы белән расланган

форма буенча Фикер каршылыкларын карау комиссиясенә алга таба карау өчен рәсми рәвештә тәкъдим итәләр.

Фикер каршылыкларын карау комиссиясе утырышы нәтиҗәләре буенча карар проекты Дәүләт комитеты идарәсе утырышына чыгарыла.»;

25 пунктта «20 декабрьдә» сүзләрен «1 ноябрьдә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге